# Сүзлекчә

**Азык җыю урыны** – урманның бер өлеше; ул урынны кырмыскалар азык җыю өчен кулланалар.

**Азык оясы** - юлдагы зур булмаган ярдәмче оя; анда ана кырмыска да, яшь кырмыскалар да булмый, җәй айларында кулланыла.

**Азык ташучы (рус. фуражир)** – азыкны бер урыннан икенче урынга күчереп йөртүче кырмыска.

**Ана кырмыска** – йомырка салучы ана җенесле кырмыска.

**Баллы сыекча** – кырмыска азыгы, аны үлән бетләре бүлеп чыгара.

**Бүксә** - үңәчнең сукыр үсентесе. Аны шулай ук «җәмәгать ашказаны» дип тә йөртәләр. Кырмыска бүксәдә саклаган азыкны оядагы башка кырмыскаларга да бүлеп бирә.

**Бүлек** – ояның бер өлеше.

**Бүлендек гаилә** - ана гаиләдән аерылып чыккан яңа гаилә.

**Галерея** - кырмыскаларның үлән бетләре өчен булдырган яшеренү урыны.

**Гөблә (үлән бете) көтүлеге -** кырмыскалар тәрбия кылучы үлән бетләре төркеме.

**Гөмбәз** – кырмыскалыкның тышкы яктагы өске өлеше.

**Йомырка, корт, кузы** – кырмысканың үсеш чорлары.

**Кырмыска әчелеге** – кырмыскалар әлеге матдәне дошманнарыннан саклану өчен бүлеп чыгаралар.

**Кырмыскалык ишегалды** - территориянең ояга тоташкан өлеше; биредә ризык ташучы кырмыскалар агымы хасил була.

**Көтүче** – үлән бетләрен караучы эшче кырмыска.

**Күзәтүче** – азык эзләүче кырмыска.

**Мыекчалар -** тою, мәгълүматны кабул итү һәм тапшыру әгъзалары.

**Сукмак (азык сукмагы)** - кырмыскалар бу сукмактан табышны күчереп йөртәләр.

**Тәрбияче кырмыска** – йомыркалар һәм кортларны тәрбия кылучы эшче кырмыска, ул кортларга кузыдан чыгарга ярдәм итә.

**Тоннель** – ышыкланган кырмыска юлы.

**Төзүче** – кырмыскалык төзү һәм төзәтү белән шөгыльләнүче эшче кырмыска.

**«Чемодан» булып йомарлану** – кырмыскаларның бер-берсен күчереп йөртү ысулы. Күчерелә торган кырмыска, аякларын бөкләп куеп, җыйнак кына итеп йомарлана.

